ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

КАРАР

03.08.2017 ел Яр Чаллы № 2421

Түбән Суыксу авыл җирлегенең генераль планы проекты белән килешү аны Тукай районы Советына раслауга җибәрү турында

РФ Шәһәр төзелеше кодексының 28 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № l31-ФЗ Федераль закон, район Уставы, Түбән Суыксу авыл җирлегенең генераль планы проекты буенча 2017 елның 2 июлендәге халык тыңлаулары нәтиҗәләре, Тукай муниципаль районының шәһәр төзелеше буенча ведомствоара комиссиясенең 2017 елның 2 августындагы 2 утырышы 2 беркетмәсе нигезендә

**КАРАР БИРӘ:**

1. Түбән Суыксу авыл җирлегенең «Татинвестгражданпроект» ДУП тарафыннан эшләнгән һәм Түбән Суыксу авыл җирлегенең торак пунктларында халык алдында каралган Генераль план проекты белән килешергә.
2. Түбән Суыксу авыл җирлеге генераль планы проектын, халык тыңлаулары беркетмәләре һәм халык тыңлаулары нәтиҗәләре буенча бәяләмә белән Тукай районы Советына раслауга җибәрергә.
3. Әлеге карарны районның рәсми сайтында, ТР рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.
4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе вазыйфаларын
башкаручы Р.Т. Гыйзатуллина